РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«16» июня 2026 ел г. Альметьевск № 1013

Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитеты каршында Бердәм иҗтимагый торак комиссиясен төзү турында» 2025 елның 21 ноябрендәге 2741 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую кагыйдәләрен һәм тәртибен раслау турында» 2005 елның 15 апрелендәге 190 номерлы карары нигезендә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитеты каршында Бердәм иҗтимагый торак комиссиясен төзү турында» 2025 елның 21 ноябрендәге 2741 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) карарның 1 нче кушымтасында:

комиссия составына кертергә:

Дәүләтгәрәев А. С. – комиссия әгъзасы, «Үсеш департаменты» муниципаль автоном учреждениесенең төзелеш һәм техник күзәтчелек идарәсе җитәкчесе.»;

б) карарның 2 нче кушымтасында:

2 бүлекнең 2.1 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«- социаль ипотека буенча торак шартларын яхшырту өчен исәпкә алу турында гражданнарның гаризаларын карау;

- «Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую кагыйдәләрен һәм тәртибен раслау турында»Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 15 апрелендәге 190 номерлы карары нигезендә исәпкә кую турында карар кабул итү өчен гаризага кушымта итеп бирелгән анкетаның һәм документлар исемлегенең тулылыгын тикшерү;

- социаль ипотека буенча торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ гаиләләрне исәпкә алу һәм куюдан баш тарту турында тәкъдимнәр әзерләү;

- махсуслаштырылган оешмаларга тапшырыла торган социаль ипотека

заказ № 4553-940

буенча торак шартларын яхшыртуга мөрәҗәгать итүчеләр реестрын гамәлдәге законнар нигезендә килештерү;

- социаль ипотека буенча торак шартларын яхшырту өчен исәпкә алынган гаиләләрнең локаль исемлекләрен законнар нигезендә исәпкә алу эшләрен, реестрын төзү һәм алып баруның дөреслеген тикшереп тору һәм аларны тотып тору;

- социаль ипотека буенча төзелгән торак урыннарны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана торган квоталар нигезендә бүлү өчен Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитеты һәм оешмалар җитәкчеләре тарафыннан тапшырыла торган гаиләләр исемлеген килештерү.»;

2 бүлекнең 2.2 пунктындагы 9 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9) Россия Федерациясе гражданнары булган яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү, шул исәптән аларны торак урыннарга мохтаҗ дип тану.»;

2 бүлекнең 2.2 пунктына түбәндәге эчтәлекле 12 пунктча өстәргә:

«12) авыл җирендә яшәргә һәм эшләргә теләк белдергән гражданнарның, яшь гаиләләрнең һәм яшь белгечләрнең торак шартларын яхшыртуга федераль программаларны гамәлгә ашыру кысаларында торак урыннарындагы йөкләмәләрне бетерү һәм шартларны үтәү турында Россия Федерациясе гражданнары гаризаларын карау.»;

3 бүлекнең 3.9 пунктындагы икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Беркетмәгә комиссиянең барлык әгъзалары кул куя һәм электрон документ әйләнеше системасы (СЭД) аша килештерү өчен җибәрелә. Беркетмә килештерелгәннән соң комиссия тарафыннан чыгарыла:»;

3 бүлекнең 3.9 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«- торак урынны социаль наем шартнамәсен төзү/өзү турында карар;

- торак урынны хезмәт урыны дип тану һәм хезмәт торак урынына наем шартнамәсе төзү турындагы карар;

- хезмәт торак урынына наем шартнамәсен өзү турында карар;

- торак урынга наем шартнамәсен төзү/өзү турындагы карарлар;

- торак урынны махсуслаштырылган торак фондына кертү һәм маневр фондының торак урынына наем шартнамәсе төзү турындагы карар;

- маневр фондының торак урынына наем шартнамәсен өзү турындагы карар;

- аз керемлеләр һәм торак исәбенә кую өчен мохтаҗлар дип тану турында күрсәтмә;

- социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урынга мохтаҗлар дип тану турында күрсәтмә;

- социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урынга мохтаҗлар дип танудан баш тарту турындагы күрсәтмә;

- социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗлар дип тану турындагы күрсәтмә;

- мохтаҗларны исемлектән төшереп калдыру турындагы күрсәтмә;

- хезмәт торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗлар дип тану турында күрсәтмә;

- хезмәт торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗлар дип танудан баш тарту турындагы күрсәтмә;

- торак сертификаты алу хокукына ия күпбалалы гаиләләрне исемлеккә

кертү турында күрсәтмә;

- социаль ипотека программасы буенча торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә алу турында күрсәтмә;

- социаль ипотека программасы буенча торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә алудан баш тарту турында күрсәтмә;

- бюджет өлкәсе хезмәткәрләрен яңадан теркәү турында күрсәтмә.».

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль эшләр буенча урынбасары Ф.Ф. Мортазинга йөкләргә

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе А.М. Каюмов